ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» ноября 2025 г. № 291

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 апрелендә кабул ителгән, 108нче номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга Әгерҗе муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарын уңайлы торак һәм коммуналь шартлар белән тәэмин итү турындагы "Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендә кабул ителгән, 1710 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 7 ноябрендә кабул ителгән 1509нче карарына ярашлы рәвештә, "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17декабрендә кабул ителгән 1050нче карарына үзгәрешләр кертү турында", Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү" дәүләт программасын раслау турында " 2019 елның 3октябрендә кабул ителгән 888нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 апрелендә 108нче карары белән расланган «2020-2025 елларга Әгерҗе муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 апрелендә 108 карары белән расланган «2020-2025 елларга Әгерҗе муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасының 1 нче кушымтасының 15 пунктына түбәндәге эчтәлекле «пунктчасы өстәргә: и) яшь гаиләдәге бер яисә ике ата-ананың да, тулы булмаган яшь гаиләдә берсенең Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуын раслаучы документның күчермәсе (алга таба-махсус хәрби операция) (булган очракта);

1.2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 июнендә 144 карары белән расланган «2020 - 2025 елларга Әгерҗе муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына 1 нче кушымтаның 24 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «24. Социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлеге планлаштырыла торган елда Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне тану датасын исәпкә алып төзелә. Беренче чиратта күрсәтелгән исемлекләргә 2005 елның 1 мартына кадәр торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган чарада катнашучы яшь гаиләләр, шулай ук өч һәм аннан күбрәк баласы булган яшь гаиләләр, шулай ук ире яисә икесе дә, яки тулы булмаган гаиләдә ата – ананың берсе махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) яшь гаиләләр кертелә»;

1.3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 апрелендә 108 карары белән расланган «2020-2025 елларга Әгерҗе муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына 3 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле «17» пункт өстәргә: «17) яшь гаиләдәге ата-ананың берсе яисә икесе дә, тулы булмаган яшь гаиләдә берсе махсус хәрби операциядә катнашуы турында документның күчермәсе (булган очракта).»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан башлап барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **И. Х. Салихов**